ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**Приказ** **Боерык**

31.10.2022 Казан ш. № 378-од

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының ведомство бүләкләре турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 22 статьясы, «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

**боерам:**

Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

«Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының Мактау кәгазе» ведомство бүләге турында нигезләмә (1 нче кушымта);

«Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының Рәхмәт хаты» ведомство бүләге турында нигезләмә (2 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының ведомство бүләге белән бүләкләүгә кандидатны тәкъдим итү формасы (3 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының Рәхмәт хаты белән бүләкләүгә тәкъдим итү формасы (коллектив өчен) (4 нче кушымта);

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык формасы һәм тарату өчен шәхси мәгълүмат субъекты рөхсәт иткән шәхси мәгълүматны эшкәртүгә рөхсәт формасы (5 нче кушымта).

2. Бүләкләүгә материаллар әзерләү эшен оештыруны, ведомство бүләкләрен исәпкә алуны һәм бирүне дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторына йөкләргә.

Рәис Ф.С. Батков

Татарстан Республикасы
Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитетының 2022
елның 31 октябрендәге
№378-од номерлы
боерыгына 1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының Мактау кәгазе» ведомство бүләге турында
нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының Мактау кәгазе (алга таба – Мактау кәгазе) Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының (алга таба – Дәүләт комитеты) ведомство бүләге булып тора.

2. Дәүләт комитетының Мактау грамотасы белән хезмәттә югары күрсәткечләргә ирешкән һәм Дәүләт комитетына йөкләнгән бурычларны хәл итүдә актив катнашкан һәм ярдәм күрсәткән, табигатьне саклау эшчәнлегендә кимендә өч ел эшләгән Дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре, Дәүләт комитеты хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка башкарма органнары хезмәткәрләре, шулай ук оешма җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре һәм башка гражданнар бүләкләнә.

3. Мактау грамотасы белән бүләкләү Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе (алга таба - Рәис) боерыгы белән, Рәис урынбасарларының, Дәүләт комитетының структур бүлекчәләре җитәкчеләренең, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка башкарма органнары җитәкчеләренең, шулай ук табигатьне саклау эшчәнлеге оешмалары җитәкчеләре һәм коллективларының язма үтенече буенча гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән үтенечнамә инициаторларының һәркайсы, Мактау кәгазе белән бүләкләү турындагы мәсьәләне карау өчен, Дәүләт комитетына түбәндәге документларны тапшыра:

үтенеч язуы;

әлеге боерыкка 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча бүләкләнүче затның конкрет хезмәтләре һәм казанышлары тасвирлап бирелгән тәкъдим итү;

әлеге боерыкка 5 нче кушымта нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык һәм тарату өчен шәхси мәгълүмат субъекты рөхсәт иткән шәхси мәгълүматны эшкәртүгә рөхсәт.

5. Мактау кәгазе белән бүләкләү турындагы материаллар Дәүләт комитетының бүләкләү материалларын карау комиссиясе утырышында карала.

6. Мактау кәгазе Рәис тарафыннан Дәүләт комитеты коллегиясе утырышларында яисә тантаналы чараларда (һөнәри бәйрәмнәр, юбилей даталары) тапшырыла.

7. Мактау кәгазе белән бүләкләнгән Дәүләт комитеты хезмәткәренең хезмәт кенәгәсенә бүләкләү турында язма кертелә.

8. Моннан алдагы бүләкне алганнан соң кимендә бер ел узгач, күрсәткән яңа хезмәтләре өчен чираттагы Мактау кәгазе белән бүләкләргә мөмкин.

9. Мактау кәгазен югалткан очракта, аның дубликаты бирелми. Мактау кәгазе белән бүләкләү турындагы боерыкның күчермәсе Дәүләт комитетының дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы тарафыннан бирелә.

Татарстан Республикасы
Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитетының 2022
елның 31 октябрендәге №
378-од номерлы боерыгына 2
нче кушымта

«Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының Рәхмәт хаты» ведомство бүләге турында
нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының Рәхмәт хаты (алга таба – Рәхмәт хаты) Татарстан Республикасының табигатьне саклау комплексын камилләштерүгә, табигатьне саклау эшчәнлегендә яңа инновацион технологияләрне үстерүгә конкрет мөһим шәхси өлеш керткәне, Татарстан Республикасының биологик төрлелеген саклауда актив катнашканы һәм булышлыгы өчен, Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында (алга таба – Дәүләт комитеты) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен, Дәүләт комитеты хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка башкарма органнары хезмәткәрләрен, шулай ук табигатьне саклау эшчәнлеге оешмалары җитәкчеләрен һәм хезмәткәрләрен, шулай ук башка гражданнарны бүләкләү булып тора.

2. Рәхмәт хаты белән кызыксындыру Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе (алга таба - Рәис) боерыгы белән, Рәис урынбасарларының, Дәүләт комитетының структур бүлекчәләре җитәкчеләренең, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка башкарма органнары җитәкчеләренең, шулай ук табигатьне саклау өлкәсе оешмалары җитәкчеләре һәм коллективларының язма үтенече буенча гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән үтенечнамә инициаторларының һәркайсы, Рәхмәт хаты белән бүләкләү турындагы мәсьәләне карау өчен, Дәүләт комитетына түбәндәге документларны тапшыра:

үтенеч язуы;

әлеге боерыкка 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча бүләкләнүче затның конкрет хезмәтләре һәм казанышлары тасвирлап бирелгән тәкъдим итү;

әлеге боерыкка 5 нче кушымта нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык һәм тарату өчен шәхси мәгълүмат субъекты рөхсәт иткән шәхси мәгълүматны эшкәртүгә рөхсәт.

4. Рәхмәт хаты белән бүләкләү (коллектив өчен) үтенеченә түбәндәгеләр беркетелә:

үтенеч язуы;

әлеге боерыкка 4 нче кушымта нигезендәге форма буенча тәкъдим итү;

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкның күчермәсе;

гамәлгә кую документының (устав яки нигезләмә) 1, 2 нче битләренең күчермәсе.

5. Рәхмәт хаты белән кызыксындыру турындагы материаллар Дәүләт комитетының бүләкләү материалларын карау комиссиясе утырышында карала.

6. Рәхмәт хаты Рәис тарафыннан Дәүләт комитеты коллегиясе утырышларында яисә тантаналы чараларда (һөнәри бәйрәмнәр, юбилей даталары) тапшырыла.

7. Рәхмәт хаты белән бүләкләнгән Дәүләт комитеты хезмәткәренең хезмәт кенәгәсенә бүләкләү турында язма кертелә.

8. Моннан алдагы бүләкне алганнан соң кимендә бер ел узгач, күрсәткән яңа хезмәтләре өчен чираттагы Рәхмәт хаты белән бүләкләргә мөмкин.

9. Рәхмәт хатын югалткан очракта дубликат бирелми. Рәхмәт белдерү турындагы боерыкның күчермәсе Дәүләт комитетының дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы тарафыннан бирелә.

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2022 елның 31 октябрендәге № 378-од номерлы боерыгына 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының
ведомство бүләге белән бүләкләүгә кандидатны
тәкъдим итү

______________________________________________________________________________
(бүләкнең исеме)

1. Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы – булганда) ________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(паспорт буенча тутырыла)

2. Вазыйфасы һәм эш, хезмәт урыны _______________________________________
______________________________________________________________________________
(вазыйфасының исемен, эш урынының, хезмәтнең һәм структур бүлекчәнең төгәл исемен күрсәтегез)

3. Җенесе ______________________________________________________________________

4. Туган көне һәм урыны ______________________________________________________
______________________________________________________________________________

5. Милләте _____________________________________________________________________

6. Белеме ______________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(уку йортының исемен, тәмамлау елын, белгечлеген күрсәтергә)
______________________________________________________________________________

7. Гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме, махсус исеме ___________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

8. Нинди дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән, бүләкләү датасы __________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

9. Кызыксындыруларның, бүләкләрнең башка төрләре
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

10. Өй адресы, элемтә телефоны _______________________________________

11. Үткәндәге эше:

| Урнашу һәм китү ае, елы | Вазыйфасы, эш урыны, учреждение, оешманың урнашу урыны |
|---|---|
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |

12. Гомуми хезмәт стажы ______________________________________________

Әлеге өлкәдә хезмәт стажы ____________________________________________

Әлеге коллективта хезмәт стажы ________________________________________

13. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының ведомство бүләге белән бүләкләүгә тәкъдим ителүчесенә характеристика.

14. Орган (оешма) җитәкчесе

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

(органның, оешманың исеме, вазыйфасы күрсәтелә)

_______________________________________________

имза Ф.И.А.

20__ елның «__» ____________

М.У. (булган очракта)

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2022 елның 31 октябрендәге № 378-од номерлы боерыгына 4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының Рәхмәт хаты белән бүләкләүгә
тәкъдим итү

1. Коллективы бүләкләүгә тәкъдим ителгән орган (оешма) исеме

_______________________________________________________________

(нигезләмә, органның, оешманың гамәлгә кую документлары нигезендә тутырыла)

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

2. Коллективы бүләкләүгә тәкъдим ителгән орган (оешма) эшчәнлегенең төп төре (төрләре) ______________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

3. Оешу датасы ______________________________________________________

4. Орган (оешма) коллективының булган дәүләт бүләкләре, кызыксындырулары төрләре ____________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

5. Юридик адресы, элемтә телефоны ___________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

6. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының Рәхмәт хаты белән бүләкләүгә органның (оешманың) коллективына характеристика

_______________________________________________________________

(хезмәтләрен (казанышларын) күрсәтеп, ирекле формада тутырыла)

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

Орган (оешма) җитәкчесе

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

(органның, оешманың исеме, вазыйфасы күрсәтелә)

_______________________________________________

имза Ф.И.А.

20__ елның «__» ___________

М.У. (булган очракта)

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2022 елның 31 октябрендәге № 378-од номерлы боерыгына 5 нче кушымта

(Тәкъдим ителә торган форма)

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин, ____________________________________________ ________________
(бүләкләнүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

__________________________________________________________________________
(шәхесне раслый торган документ сериясе, номеры, бирү датасы, документны биргән дәүләт органының исеме)

теркәлү адресы: ____________________________________________________________,

________________________________________________________________________________

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә 420021, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Кәрим Тинчурин урамы, 29 адресында урнашкан Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында бары тик түбәндә санап кителгән шәхси мәгълүмат категорияләренә генә кагылышлы шәхси мәгълүматларымны эшкәртергә ризалыгымны бирәм:

фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)
туган көне, ае, елы;
шәхесне раслый торган документ төре;
шәхесне раслый торган документ белешмәләре;
яшәү урыны;
элемтә өчен телефон номеры;
почта адресы.

Мин бүләкләнүче затларның мәгълүматлар базасын формалаштыру һәм алып бару максатларында гына шәхси мәгълүматларны куллануга ризалыгымны бирәм.

Әлеге ризалык минем тарафтан югарыда күрсәтелгән максатларга ирешү өчен кирәк булган шәхси мәгълүматларыма карата, җыю, системалаштыру, туплау, саклау, ачыклау (яңарту, үзгәртү), тапшыру, куллануны кертеп гамәлләр башкаруга, шулай ук Россия Федерациясе законнарында каралган теләсә кайсы башка гамәлләрне башкаруга бирелә.

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты минем шәхси мәгълүматларымны Россия Федерациясе законнары нигезендә һәм автоматлаштырылмаган, һәм автоматлаштырылган ысуллар белән эшкәртүне гарантияли.

Әлеге ризалык шәхси мәгълүматны эшкәртү максатларына ирешкәнче яки мәгълүматны саклау вакыты дәвамында гамәлдә.

Бу ризалык теләсә кайсы вакытта минем язма гариза буенча кире алынырга мөмкин.

«__» ___________20__ ел _______________/____________________/
(имза) (имзаның расшифровкасы)

(Тәкъдим ителә торган форма)

Шәхси мәгълүмат субъекты тарату өчен рөхсәт иткән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин, ________________________________________ _______________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

_________________________________________________________________________,
(почта адресы)

_________________________________________________________________________,
(электрон почта адресы)

_________________________________________________________________________,
(телефон номеры)

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 10.1 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына (ОГРН 1081690013569, ИНН 1660111252), юридик адресы: 420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Кәрим Тинчурин ур, 29, Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының рәсми сайтында (https://ojm.tatarstan.ru/) урнаштыру максатында шәхси мәгълүматларымны таратуга (тапшыруга, бирүгә) үз ризалыгымны бирәм.

Эшкәртү өчен ризалык бирелә торган шәхси мәгълүматлар категорияләре һәм Исемлеге

| /б № | Шәхси мәгълүматлар | Ризалык | |
|---|---|---|---|
| | | әйе | юк |
| | Гомуми шәхси мәгълүматлар | | |
| | Фамилиясе | | |
| | Исеме | | |
| | Атасының исеме (булганда) | | |
| | Женесе | | |
| | Гражданлыгы | | |
| | Туган көне, ае, елы һәм туган урыны | | |
| | Шәхесне раслый торган документ реквизитлары (документ төре, аның сериясе һәм номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән) | | |
| | Яшәү урыны, теркәлү урыны | | |
| | Телефон, шул исәптән кесә телефоны номеры | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Электрон почта адресы | | |

Шартлар һәм тыюлар билгеләнә торган шәхси мәгълүматлар категорияләре һәм исемлеге (шәхси мәгълүматлар субъектының теләге буенча тутырыла)

| /б № | Шәхси мәгълүматлар | Билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге |
|---|---|---|
| 1. (Шәхси мәгълүматлар категориясе) | | |
| | (Шәхси мәгълүматлар исемлеге) | |

Чикләнмәгән даирәдәге затларга файдалану мөмкинлеге бирелачәк һәм субъектның персональ мәгълүматлары белән бүтән гамәлләр башкарылачак операторларның мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр: https://ojm.tatarstan.ru/.

Әлеге ризалык имзаланганнан алып 1 (бер) ел гамәлдә була.

Шәхси мәгълүматлар субъекты үзенең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә әлеге ризалыгын, операторларга язмача хәбәр итеп, кире алырга хокуклы.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык кире алынган очракта, оператор аларны эшкәртүне туктатырга яки мондый эшкәртүне туктатуны тәэмин итәргә тиеш (әгәр шәхси мәгълүматны эшкәртү оператор кушуы буенча эш итүче башка зат тарафыннан башкарылса) һәм шәхси мәгълүматларны саклау шәхси мәгълүматларны эшкәртү максатлаы өчен башка кирәк булмаган очракта, күрсәтелгән кире алу кергән көннән утыз көннән дә артмаган срокта шәхси мәгълүматларны гамәлдән чыгарырга яки аларны гамәлдән чыгаруны тәэмин итәргә (әгәр шәхси мәгълүматларны эшкәртү оператор кушуы буенча эш итүче башка зат тарафыннан башкарылса) тиеш.

Күрсәтелгән вакыт эчендә шәхси мәгълүматларны гамәлдән чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор мондый шәхси мәгълүматларны блокировкалауны гамәлгә ашыра яки аларны блокировкалауны тәэмин итә (әгәр шәхси мәгълүматларны оператор кушуы буенча эш итүче башка зат эшкәртә икән) һәм шәхси мәгълүматларны күп дигәндә алты ай вакыт эчендә гамәлдән чыгаруны тәэмин итә.

Моның белән «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның нигезләмәләре белән танышуымны, шәхси мәгълүматларны яклау өлкәсендәге хокуклар һәм бурычлар миңа аңлатылганын раслыйм.

«__» ___________20__ ел _______________/_____________________/
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Искәрмә. Шартлар һәм тыюлар операторлар тарафыннан чикләнмәгән яки билгеле бер даирәдәге затларга шәхси мәгълүматларны тарату һәм (яки) бирү буенча гамәлләрне башкаруны чикләү яки тыюны да күздә тота.

Ризалыкта өстәмә рәвештә алынган шәхси мәгълүматлар шәхси мәгълүматларны эшкәртүче операторлар тарафыннан бары тик анық катгый билгеләнгән хезмәткәрләргә генә керү мөмкинлеге тәэмин ителә торган эчке челтәре буенча, яисә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен кулланып, яисә алынган шәхси мәгълүматларны тапшырмыйча гына тапшырыла ала торган шартлар күрсәтелергә мөмкин.